# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# ТҮБӘН УРЫСБАГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**28 октябрь 2023ел** **№1**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Түбән Урысбага авыл җирлегенең Түбән Урысбага торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Зеленодольск муниципаль районы Түбән Урысбга авыл җирлегенең Түбән Урысбага торак пунктында гражданнар җыены үткәрү турында Карар кабул итте:

1. Мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары, 1 төркем инвалидлар, күп балалы гаиләләрдән тыш, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Түбән Урысбага авыл җирлегенең Түбән Урысбага торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1. авыл җирлеге чикләрендә автомобиль юлларын, күпер корылмаларын ремонтлау, төзекләндерү һәм карап тоту, инерт материаллары сатып алу;

2. су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу һәм кое челтәрләрен төзү, ремонтлау һәм карап тоту;

3. урам утларын ремонтлау, карап тоту һәм паспортлаштыру, шул исәптән чыгым материалларын һәм комплектлау материалларын сатып алу;

4. территорияләрне (һәйкәлләрне, зиратларны, контейнер мәйданчыкларын, санкцияләнмәгән чүплекләрне, чишмәләрне, балалар һәм спорт мәйданчыкларын, агач кисүне) һәм тышкы төзекләндерү объектларын (һәйкәлләрне, зиратларны, контейнер мәйданчыкларын) төзү, карап тоту (төзекләндерү) һәм ремонтлау, шул исәптән әлеге максатлар өчен төзелеш материалларын һәм кече архитектура формаларын сатып алу, эшләтү;

5. урамнарны һәм тышкы төзекләндерү объектларын техник паспортлаштыру;

6. смета документларын әзерләү, төзелеш контролен гамәлгә ашыру.

7. су алу манарасын сатып алу.

3. Әлеге карарны, кабул иткәннән соң 10 көн эчендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга .http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru һәм шулай ук Түбән Урысбага авылы, Үзәк урамы, 62а йорт (җирлек хакимияте бинасы), Түбән Урысбага авылы, Үзәк урамы, 63а йорт (мәдәният йорты бинасы) адреслары буенча урнашкан Түбән Урысбага авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштырырга.

**Халык җыенында рәислек итүче** **Х.Х.Сибгатуллин**.